КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 март г.Казань № 286

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2028 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегияне раслау турында» 2021 ел, 24 декабрь, 1285 нче карары белән расланган 2022 – 2028 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегиягә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2028 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегияне раслау турында» 2021 ел, 24 декабрь, 1285 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 27 декабрь, 1422 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2022 – 2028 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегиягә (алга таба - Стратегия) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекнең утыз дүртенче абзацындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе вазыйфасын били.»;

II бүлектә:

2.3 бүлекчәнең алтынчы абзацында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2.4 бүлекчәдә:

дүртенче абзацта «бюджеттан тыш фондлар» сүзләреннән соң «, дәүләт юридик бюросы» сүзләрен өстәргә;

унөченче - ундүртенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

уналтынчы абзацта «, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан оештырылган. Түләүсез юридик ярдәмнең сыйфатын мониторинглау

максатларында Министрлык гражданнар белән кире элемтә оештырды.” сүзләрен төшереп калдырырга;

егерме бишенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының Дәүләт-хокук идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе» сүзләренә алмаштырырга, «Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәләре» сүзләренә алмаштырырга;

IV бүлекнең 4.3 бүлекчәсендә:

унөченче абзацта «урта һөнәри белем бирү мәгариф оешмаларында» сүзләрен «һөнәри белем бирү оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

ундүртенче абзацта «урта һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары» сүзләрен «һөнәри белем бирү оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

унтугызынчы абзацта икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында 2020 елдан ел саен республиканың дәүләт медицина оешмаларында эшләүче медицина хезмәткәрләре өчен торак бирелә.», өченче җөмләне төшереп калдырырга;

VII бүлекнең 7.3 бүлекчәсенең уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021 елдан башлап профилактик хисапта торучы яшүсмерләрне ресоциализацияләүгә юнәлдерелгән «Свои» проекты тормышка ашырыла. «Свои» проектының максаты - яшүсмерләр җинаятьчелеген киметү һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларның кабат очракларын булдырмау, авыр тормыш хәлендә калган яшүсмерләрне социаль файдалы эшчәнлеккә җәлеп итү. Проект кысаларында рәсми булмаган белем бирү учреждениеләре тренерлары, психологлар, спорт түгәрәкләре, яшүсмерләр клублары хезмәткәрләре эшкә җәлеп ителә һәм яшүсмерне ресоциализацияләү буенча ярдәм маршрут төзелә.»;

VIII бүлекнең 8.1 бүлекчәсендә:

дүртенче абзацта «сыйфатлы белем бирү хезмәт күрсәтүләренә» сүзләрен «сыйфатлы белем бирүгә» сүзләренә алмаштырырга;

егерме тугызынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

Стратегиягә кушымтада:

1.2 пунктның «дәүләт телләрендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү» юлының 4 графасына «Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары» сүзләреннән соң «, Дәүләт юридик бюросы ДКУ» сүзләрен өстәргә;

2.1 пунктның 4 графасында «Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктның 4 графасында «Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктның 4 графасында «Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктның 4 графасында «Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктның «чит ил гражданнарын (мигрантларны) социаль-мәдәни адаптацияләү буенча конкрет чаралар һәм программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру» юлының 4 графасында «Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департаменты» сүзләрен Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «2.7. | Дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының дини оешмалар белән дин тотучыларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә, фәнни һәм эксперт җәмгыяте вәкилләрен дини өлкәдәге вәзгыятьне аңларга актив җәлеп итүгә юнәлдерелгән мәсьәләләр буенча үзара хезмәттәшлеге | Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алу хокукына конкурсларда, шулай ук гражданлык бердәмлеген ныгытуга һәм милләтара мөнәсәбәтләрне гармонизацияләүгә юнәлдерелгән коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган оешмаларның иҗтимагый проектларына ярдәм итүгә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга һәм министрлыклар һәм ведомстволарның башка конкурсларында дини оешмаларның катнашуына ярдәм итү юлы белән социаль проектларга һәм дини берләшмәләр инициативаларына ярдәм итү | Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департаменты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы (килешү буенча), Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (килешү буенча), Татарстан митрополиясе (килешү буенча) | грант ярдәме алган проектлар саны |
| | | дин әһелләрен укытуны оештыруга, квалификацияләрен күтәрүгә һәм яңадан әзерләүгә ярдәм итү | Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департаменты (килешү буенча); РИИ (килешү буенча), Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (килешү буенча), Татарстан митрополиясе (килешү буенча) | дини белеме булган мәхәлләләр җитәкчеләре өлеше (процентларда) |
| | | форумнарын үткәрүне оештыруда «Милли үзенчәлек һәм дин» татар дин әһелләре, православие җәмәгатьчелеге катнашу | БТК башкарма комитеты (килешү буенча), ТР мөселманнары Диния нәзарәте (килешү буенча), Татарстан Республикасы Рәисенең | чараларда катнашучылар саны |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департаменты (килешү буенча), Татарстан митрополиясе (килешү буенча) | |
| | | этноконфессиональ өлкәдә дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеген эксперт һәм фәнни яктан тәэмин итү | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе (килешү буенча) | эксперт бәяләмәләре, белешмәләр һәм язмалар саны»; |

6.10 пункттагы «Тернәкләндерү вакытында инвалидларның мөмкинлекләрен киңәйтү» юлының 4 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге (килешү буенча)»;

8.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «8.2. | Гражданнарга хокукый мәгълүмат җиткерү | авыл җирлегендә яшәүче социаль якланмаган, аз керемле гражданнарны һәм авыр тормыш хәлендә калган гражданнарны хокукый ярдәм күрсәтү өчен ерактан торып (видеоконференция режимында) кабул итүне оештыру һәм үткәрү | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, Дәүләт юридик бюросы ДКУ, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | видеоконференция режимында консультация ярдәме күрсәтелгән гражданнар өлеше, аны сорап мөрәҗәгать итүчеләрнең гомуми санында, процент |
| | | гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең «кайнар линия» эшләве | Дәүләт юридик бюросы ДКУ | уздырылган юридик консультацияләр саны»; |

8.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «8.3. | Хокукый ярдәм күрсәтү буенча чыгуларны оештыру | күчмә мәгълүмат-консультация төркеменең хокукый тематикасы буенча гражданнарны кабул итү (күчмә кабул итүләр) | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, Дәүләт юридик бюросы ДКУ, «Россия юристлары ассоциациясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе (килешү буенча), «Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә төбәк җәмәгать контроле үзәге» коммерциячел булмаган партнерлыгы (килешү буенча) | хокукый ярдәме күрсәтелгән гражданнар өлеше, аны сорап мөрәҗәгать итүчеләрнең гомуми санында, процент |
| | | эшкуарлык эшчәнлеге алып баруның хокукый проблемалары буенча муниципаль берәмлекләрдә күчмә киңәшмәләр, семинарлар уздыру | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе (килешү буенча) | үткәрелгән күчмә чаралар саны |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | муниципаль берәмлекләрдә, республика оешмаларында хезмәт законнары мәсьәләләре буенча күчмә чаралар үткәрү, хезмәткәрләргә консультацияләр бирү, шул исәптән күчмә юридик кабул итү бүлмәләре кысаларында | Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе (килешү буенча) | уздырылган чаралар саны, хокукый ярдәм күрсәтелгән хезмәткәрләр саны»; |

8.4 пункттагы «Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында хокукый белемнәрне тарату максатларында мәгариф оешмаларының, фәнни-тикшеренү учреждениеләренең, аспирантларның һәм мәгариф оешмалары студентларының профессор-укытучылар составы арасында Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру темасына фәнни-гамәли тикшеренү эшләре конкурсын үткәрүне оештыру» юлының 4 графасында сүзләрен «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

файдаланылган кыскартулар исемлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт юридик бюросы ДКУ - «Татарстан Республикасы Дәүләт юридик бюросы» дәүләт казна учреждениесе.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин